КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 июнь г.Казань № 737

Республика башкарма хакимият органнарының кара-каршы инвестиция йөкләмәләре белән контракт төзү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның $111^4$ статьясын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Республика башкарма хакимият органнарының кара-каршы инвестиция йөкләмәләре белән контракт төзү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеге тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 22 июнь, 737 нче
карары белән расланды

Республика башкарма хакимият органнарының
кара-каршы инвестиция йөкләмәләре белән контракт төзү
мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеге
тәртибе

1. Әлеге Тәртип нәтиҗәләргә карап кара-каршы инвестиция йөкләмәләре белән контракт төзелә торган сатып алуларны гамәлгә ашыру турында карар кабул иткәндә республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген координацияләү һәм аларның үзара хезмәттәшлеге мәсьәләләрен җайга сала.

2. Дәүләт контракты төзү турындагы мәсьәләне карап тикшерү сатып алуны планлаштыручы республика башкарма хакимият органы гаризасы (алга таба – гариза бирүче, гариза) нигезендә гамәлгә ашырыла, әлеге сатып алу нәтиҗәләренә карап Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгына (алга таба – Агентлык) җибәрелә торган дәүләт контракты төзелә.

Агентлык гаризаны терки һәм гариза кергән көнне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2019 ел, 20 февраль, 118 нче карары нигезендә «Татарстан инвестицияләрен контрольдә тоту» мәгълүмат системасына аның турында белешмә кертә.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның $111^4$ статьясындагы 2 өлешендә каралган белешмәләрне һәм җитештерүгә булдырылырга, модернизацияләнергә, үзләштерелергә тиешле товарның «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән Россия Федерациясе территориясендә сәнәгать продукциясен җитештерүне раслау критерийларына туры килүе турында белешмәләрне чагылдыра торган белешмә кәгазе;

стратегик планлаштыру документларында билгеләнгән өстенлекләр һәм максатлар нигезендә көтелә торган нәтиҗәләрне тасвирлап, товар җитештерүне булдыру, модернизацияләү, үзләштерү һәм (яки) Татарстан Республикасы территориясендә хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән мөлкәтне (күчемсез мөлкәтне яки үзара технологик бәйле булган күчемсез мөлкәт белән күчемле мөлкәтне) булдыру, реконструкцияләү нәтиҗәлелеге нигезләмәсе;

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның $111^4$ статья-

сындагы 3 өлешендә күрсәтелгән шартлар булган дәүләт контракты проекты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәүләт контракты төзүгә электрон конкурс уздыру турындагы боерыгы проекты (алга таба – боерык проекты).

3. Агентлык гариза кергән көннән өч эш көненнән артмаган срокта:

гаризаны терки;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган документларны карап тикшерә;

әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган нигезләр булган очракта, гаризаны канәгатьләндерү турында яки гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

4. Гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез була:

тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәне ачыклау;

гариза бирүче тарафыннан әлеге Тәртипнең 2 пункты таләпләре бозылган документларны тапшыру;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау.

5. Агентлык әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә тиешле карар кабул ителгән көннән өч эш көненнән артмаган срокта Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы ярдәмендә республика башкарма хакимият органнарына, әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, рәсми сораулар җибәрә:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына – бирелә торган мәгълүматның Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килүкилмәвенә;

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына – «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларына туры килүкилмәвенә.

6. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән республика башкарма хакимият органнары әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән рәсми сораулар алынган көннән 10 эш көне эчендә Агентлыкка рәсми сорала торган мәгълүматны тапшыра.

7. Агентлык әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән рәсми сорала торган мәгълүматны алган көннән биш эш көне эчендә:

нәтиҗәләренә карап, сатып алуны гамәлгә ашыру турында карар кабул ителә алган инвестиция проектының техник һәм финанс-икътисадый параметрларына анализ ясый;

потенциаль инвесторлар эзләүне гамәлгә ашыра;

нәтиҗәләренә карап, сатып алуларны гамәлгә ашыру турында дәүләт контракты төзелә алган Татарстан Республикасы өчен инвестиция проектын гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгы (максатка ярашсызлыгы) турында якынча җыелма бәяләмә (алга таба – бәяләмә) әзерли.

8. Уңай бәяләмә бирелгән очракта, Агентлык аны, әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә бәяләмә әзерләгән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза

бирүчегә җибәрә.

9. Гариза бирүче бәяләмә алган көннән 10 эш көне эчендә, Агентлык һәм Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән килештереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты турындагы нигезләмәне раслау турында» 2005 ел, 5 декабрь, 563 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда боерыклар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

10. Боерык проектында «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның $111^4$ статьясындагы 2 өлешендә каралган мәҗбүри белешмәләр булырга тиеш.